**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 18 апрель № 266

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру турында» 2008 ел, 10 ноябрь, 799 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру турында» 2008 ел, 10 ноябрь, 799 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 12 октябрь, 804 нче; 2012 ел, 21 июнь, 538 нче; 2014 ел, 1 февраль, 56 нчы; 2014 ел, 29 апрель, 278 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына хезмәткәрләрне, шул исәптән оешмалар җитәкчеләрен, шулай ук эш бирүчеләр – индивидуаль эшмәкәрләрне хезмәтне саклау буенча өйрәтүне, аларның хезмәтне саклау таләпләрен белүләрен тикшерүне оештыруны гамәлгә ашырырга, шул исәптән:

республикада хезмәтне саклау мәсьәләләре буенча эш бирүчеләрне һәм оешмалар хезмәткәрләрен өйрәтүне гамәлгә ашыручы оешмаларның мәгълүматлар банкын формалаштырырга;

Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән оешмаларның һәм учреждениеләрнең эш бирүчеләрен һәм хезмәткәрләрен хезмәтне саклау буенча өйрәтүне гамәлгә ашыручы оешмаларның хезмәтне саклау буенча уку-укыту планнарын һәм өйрәтү программаларын килештерү буенча эш алып барырга;

икътисадый эшчәнлек төрләре, муниципаль берәмлекләр яктылыгында һәм тулаем республика буенча эш бирүчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең хезмәтне саклау таләпләрен белүләренә тикшерү үткәрүгә һәм аларны өйрәтүгә мониторинг гамәлгә ашырырга.»;

3 нче пункт үз көчен югалткан дип санарга;

әлеге карар белән расланган Хезмәтне саклау буенча республика ведомствоара комиссиясе турындагы нигезләмәне яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган Хезмәтне саклау буенча республика ведомствоара комиссиясе составын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\266.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2008 ел, 10 ноябрь, 779 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 18 апрель, 266 нчы
карары редакциясендә)

Хезмәтне саклау буенча республика ведомствоара комиссиясе
**СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Песошин Алексей Валерьевич | Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары – комиссия рәисе |
| Зарипова Эльмира Әмир кызы | Татарстан Республикасының хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры – комиссия рәисе урынбасары |
| Бәдриев Илдар Фоат улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе башлыгы – Комиссия сәркатибе |
| Анфимова Алла Леонидовна | Татарстан Республикасының финанс министры урынбасары |
| Әхмәтшин Алмаз Сәлим улы | Татарстан Республикасының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары |
| Володкевич Александр Петрович | «Казан вертолет заводы» ачык акционерлар җәмгыяте генераль директорының җитештерүне тәэмин итү, сәнәгать иминлеге, хезмәтне саклау, гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча урынбасары (килешү буенча) |
| Гайзатуллин Рамил Ринат улы | дәүләт учреждениесе – Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча региональ бүлеге идарәчесе (килешү буенча) |
| Гафаров Марат Рөстәм улы | Татарстан Республикасының Һөнәр берлекләре федерациясе рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Голубев Юрий Александрович | «АК БАРС» БАНК» ачык акционерлар җәмгыяте эшләр идарәсенең хезмәтне саклау хезмәте җитәкчесе |

| | |
|---|---|
| Зарипов Марс Миңнехан улы | Экология, технология һәм атом күзәтчелеге федераль хезмәте идарәсенең Идел буе территориаль бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Имамов Алмас Әзһар улы | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Костюшин Евгений Константинович | Татарстан Республикасында Дәүләт хезмәт инспекциясе җитәкчесе – Татарстан Республикасында баш дәүләт хезмәт инспекторы (килешү буенча) |
| Краснова Ольга Михайловна | Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Кушимов Александр Тюлегенович | «Элекон заводы» ачык акционерлар җәмгыяте идарәсе әгъзасы – генераль директоры киңәшчесе (килешү буенча) |
| Манжосова Татьяна Николаевна | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының хезмәтне саклау белән дәүләт идарә итүе бүлеге башлыгы |
| Надыршин Шамил Ягәфәр улы | «Түбән Кама нефть химиясе» ачык акционерлар җәмгыяте баш инженерының җитештерүне тикшерүдә тоту һәм сәнәгать иминлеге һәм хезмәтне саклау буенча урынбасары (килешү буенча) |
| Сабаев Петр Николаевич | «Татнефть» ачык акционерлар җәмгыяте баш инженеры урынбасары - сәнәгать иминлеге һәм хезмәтне саклау идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Степаненко Игорь Юрьевич | «КАМАЗ» ачык акционерлар җәмгыятенең Сәнәгать иминлеге һәм экология департаменты директоры (килешү буенча) |
| Титов Николай Леонидович | Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының беренче урынбасары |
| Фатыйхов Илдар Разин улы | Татарстан Республикасының сәламәтлек саклау министры урынбасары |

| | |
|---|---|
| Хөсәенов Алмаз Шәүкәт улы | Татарстан Республикасының сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары |
| Чукин Артем Викторович | Татарстан Республикасының транспорт һәм юл хуҗалыгы министры урынбасары |
| Шәрәфетдинов Рәис Мифтах улы | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының эшләр идарәчесе |
| Шром Григорий Исакович | «Казаноргсинтез» ачык акционерлар җәмгыяте баш инженерының сәнәгать иминлеге буенча урынбасары (килешү буенча). |

F:\KARAR\2015\266-1.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2008 ел, 10 ноябрь, 779 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 18 апрель, 266 нчы
карары редакциясендә)

Хезмәтне саклау буенча республика ведомствоара комиссиясе турында
**НИГЕЗЛӘМӘ**

1. Хезмәтне саклау буенча республика ведомствоара комиссиясе (алга таба – Комиссия) хезмәтне саклау өлкәсендәге проблемаларны хәл итү буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының, Татарстан Республикасындагы федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнарының (алга таба – федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары), җирле үзидарә органнарының, күзәтчелек һәм тикшерүдә тоту органнарының, һөнәр берлекләре һәм эш бирүчеләр берләшмәләренең, шулай ук республика территориясендә урнашкан оешмаларның килештерелгән гамәлләрен тәэмин итү максатларында оештырылды.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы законнарына, Россия Федерациясе Президенты указларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Президенты указларына һәм боерыкларына, Россия Федерациясе Хөкүмәте һәм федераль дәүләт хакимиятенең башка органнары карарларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башка органнары карарларына һәм боерыкларына, социаль партнерлыкның федераль, төбәкара, төбәк, тармак (тармакара) һәм территориаль дәрәҗәләрендә эш бирүчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең вәкаләтле вәкилләре арасында төзелгән социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга сала торган килешүләргә, шулай ук бу Нигезләмәгә таяна.

3. Хезмәтне саклау буенча республика ведомствоара комиссиясе турындагы нигезләмәне һәм комиссия составын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслый.

4. Комиссия Комиссия рәисе, аның урынбасары һәм Комиссия әгъзалары составында төзелә. Комиссия составына Татартан Республикасы башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының кызыксынучы территориаль органнары, һөнәр берлекләре һәм эш бирүчеләр берләшмәләре вәкилләре, шулай ук республиканың сәнәгать предприятиеләре вәкилләре керә.

5. Комиссиянең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

гражданнарның хезмәткә һәм хезмәтне саклауга конституцион хокукларын яклау, тәртип бозуларны ачыклау, кисәтү һәм бетерү мәсьәләләрендә Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының, федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнарының, җирле үзидарә органнарының, күзәтчелек һәм тикшерүдә тоту органнарының, һөнәр берлекләре һәм эш бирүчеләр берләшмәләренең үзара хезмәттәшлеген яраштыру;

җитештерүдәге имгәнүләрне, һөнәри авыруларны булдырмый калуга һәм хезмәткәрләрнең эш шартларын яхшыртуга юнәлдерелгән системалы чаралар билгеләү өлешендә Татарстан Республикасында хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

хезмәт шартлары һәм хезмәтне саклау буенча закон актларын һәм башка норматив актларны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының, җирле үзидарә органнарының, республика һөнәр берлекләре һәм эш бирүчеләр берләшмәләренең, оешмаларның хезмәтне саклау һәм хезмәт шартлары буенча эшен оештырудагы казанышларын, тәҗрибәсен һәм иң яхшы гамәлләрен популярлаштыру.

6. Комиссия үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен түбәндәгеләргә хокуклы:

Татарстан Республикасында хезмәтне саклау өлкәсендәге дәүләт сәясәтен тормышка ашыруга бәйле булган мәсьәләләрне карарга;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, күзәтчелек һәм тикшерү органнары, һөнәр берлекләре һәм эш бирүчеләр берләшмәләре җитәкчеләрен һәм башка вазыйфаи затларын, шулай ук хуҗалык субъектлары җитәкчеләрен үзенең утырышларына чакырырга;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, күзәтчелек һәм тикшерү органнарыннан, һөнәр берлекләре һәм эш бирүчеләр берләшмәләреннән, шулай ук хуҗалык субъектларыннан Комиссия компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча билгеләнгән тәртиптә материаллар һәм мәгълүматлар соратып алырга;

Комиссия компетенциясенә керә торган карарлар һәм башка материаллар әзерләүдә катнашу өчен Татарстан Республикасы министрлыклары, ведомстволары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары белгечләрен, оешмалар вәкилләрен, шулай ук фәнни хезмәткәрләрне билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә;

җитештерүдәге имгәнүләрне һәм һөнәри авыруларны, шулай ук хезмәтне саклау буенча дәүләт норматив таләпләренә туры килми торган эш урыннарын кыскартуны булдырмый калу максатларыннан чыгып, хезмәтне саклау һәм хезмәт шартлары өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү мәсьәләләре буенча карарлар кабул итәргә;

Комиссия белән әлеге органнар арасында төзелгән тиешле килешүләр нигезендә хокук саклау органнарын, дәүләт күзәтчелеген һәм тикшерүен гамәлгә ашыручы органнарны Комиссия эшенә булышлык күрсәтү өчен җәлеп итәргә,

Комиссия компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча аларга тәкъдимнамәләр бирергә;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары таләп ителә торган мәсьәләләр буенча билгеләнгән тәртиптә тәкъдимнәр кертергә;

хезмәтне саклау һәм хезмәт шартларын яхшырту эшләрен иң яхшы оештыруга республика смотр-конкурсларында җиңүчеләрне билгеләргә;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының кызыксынучы территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, күзәтчелек һәм тикшерүдә тоту органнары, һөнәр берлекләре һәм эш бирүчеләр берләшмәләре, шулай ук хуҗалык субъектлары вәкилләрен җәлеп итеп, Комиссия эшчәнлегенең аерым юнәлешләре буенча эшче төркемнәр төзергә.

7. Комиссия утырышлары Комиссия рәисе йә аның урынбасары тарафыннан, кирәк булуга карап, әмма кимендә ярты елга бер тапкыр үткәрелә. Утырышлар, әгәр дә аларда Комиссия составының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы булып санала.

8. Комиссияне Комиссия рәисе җитәкли.

Комиссия рәисе:

Комиссиягә йөкләнгән бурычларның үтәлешен оештыра;

Комиссия әгъзалары арасында, шул исәптән килешү буенча Комиссия составына керә торган әгъзалар арасында бурычлар бүлә;

Комиссия утырышларын үткәрә һәм аларда рәислек итә;

Комиссия эшчәнлеген тәэмин итә торган, шул исәптән Комиссия утырышларын үткәрү турында карарлар кабул итә.

9. Комиссиянең Комиссия утырышларында карала торган мәсьәләләре буенча карарлары ачык тавыш бирү юлы белән Комиссиянең анда катнашучы әгъзалары тавышының гади күпчелеге белән кабул ителә. Тавышлар саны тигез булган очракта, рәис тавышы хәлиткеч була.

10. Комиссия карарлары Комиссия рәисе яки аның урынбасары кул куя торган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

11. Аерым очракларда Комиссиянең барлык әгъзаларыннан сораштыру юлы белән, сораштыру нәтиҗәләрен Комиссия рәисе, ә ул булмаганда Комиссия рәисе урынбасары кул куя торган беркетмәгә кертеп, читтән торып тавыш бирү үткәрелергә мөмкин.

12. Эшчәнлекне оештыру-техник яктан тәэмин итү, утырышлар беркетмәләрен алып бару һәм Комиссия карарларын әзерләү Комиссия сәркатибе тарафыннан гамәлгә ашырыла. Сәркатип булмаса, аның бурычлары Комиссия рәисе карары буенча Комисия әгъзаларының берсенә йөкләнә.